**Дөрес сөйләм тәрбияләү эшен ничек оештырырга?**

**1.** Иң элек бала белән аралашучы һәр кеше тыныч тавыш белән, ашыкмыйча, бераз акрынрак һәм дөрес итеп сөйләшергә тиеш. Кечкенә бала белән гадәттәге темпта сөйләшергә ярамый.

**2.** Әгәр бала үз фикерен әйтеп бирә алмаса, аңа тыныч кына булышып җибәрергә кирәк.

**3.** Баланың күп “бытбылдавына” һич тә каршы килмәгез, ул шулай сөйләм органнарын күнектерә.

**4.** 3-4 яшьлек баланы укырга өйрәтергә ашыкмагыз.

**5.** Балага үз яшенә туры килми торган шигырьләр ятлату кирәкми.

**6.** Баланың озак вакыт телевизор карвы аңа файда китерми.

**7.** Балага кечкенәдән үз яшенә туры килә торган шигырьләр, әкиятләр укырга тырышыгыз.

**8.** Сөйләмдәге кимчелекләрне булдырмый калу өчен, сөйләм аппаратының нормада булуын контрольдә тотарга кирәк.

**9.** Сөйләм культурасы булдыруны да истән чыгармаска кирәк. Башкаларның сөйләмен игътибар белән тыңларга, бүлдермәскә, өлкәннәр сөйләменә катнашмаска, кирәгеннән артык кычкырып сөйләшмәскә, берәрсе ял иткәндә комачауламаска кечкенәдән үк өйрәтергә кирәк.